«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____ И.Г.Һадиуллин
«19» ноября 2025 нче ел

Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) телдән Бердәм республика имтиханын уздыру өчен күрсәтмә материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

1. Имтихан эше билгеләнеше

Контроль бәяләү материаллары урта (тулы) мәктәпне тәмамлаучы укучыларның татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты үтәлеше дәрәҗәсен билгеләү мөмкинлеген бирә.

2. Имтихан эшенең эчтәлеген билгеләүче документлар

Имтихан эшенең эчтәлеге түбәндәге документларга нигезләнеп билгеләнә:

1. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телендә сөйләшүче балалар өчен “Татар теле” предметыннан үрнәк программа. Авторлары: Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан, 2018. (электрон ресурс) // https://mon.tatarstan.ru/primernye_rabochie_programmy.htm?page=2 (мөрәҗәгать итү вакыты 15.10.2022)
2. Федеральная образовательная программа среднего общего образования// https://mon.tatarstan.ru/federalnie-osnovnie-obshcheobrazovatelnie-7050169.htm (мөрәҗәгать итү вакыты 15.10.2023)

3. Имтихан эшенең төзелеше

Татар теленнән имтихан эше тәкъдим ителгән 3 җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган – 10 бирем, җаваплар тезмәсен күрсәтү кирәк булган – 1 бирем, кыска җавап бирүне таләп иткән – 10 һәм киңәйтелгән җавап (язма текст) бирүне таләп иткән ачык типтагы 6 биремне үз эченә ала.

Татар теленнән имтихан эше дүрт өлештән гыйбарәт.

1 нче өлеш (1–6 нчы биремнәр) җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәрдән тора.

2 нче өлеш (7-11 нче биремнәр) җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәрдән тора. Бу өлештә тәкъдим ителгән биремнәр укучының текст белән эш, укып аңлау, анализлый белү осталыгын тикшерүгә юнәлдерелгән.

3 нче өлеш (12-21 нче биремнәр) – укучының лексик-грамматик белемнәрен, татар телендә сүз ясалышы мөмкинлекләрен үзләштерүен тикшерүгә юнәлдерелгән биремнәрдән тора.

4 нче өлеш (22-27 нче биремнәр) – укучының язма сөйләм осталыгын тикшерүгә юнәлтелгән ачык типтагы биремнәрне тәшкил итә.

Имтихан эшендә биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

Биремнәрнең имтихан эшендә чагылышы

1 нче таблица

Эшнең өлешләре	**Биремнәрнең саны**	**Башлангыч (максималь) иң югары балл**	**Иң югары башлангыч баллдан биремнәрнең әлеге кисәгә өчен куелган иң югары башлангыч баллның проценты**	**Биремнәрнең төрләре (типлары)**
1 нче өлеш	6	6	15	Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр
2 нче өлеш	5	5	12	Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр
3 нче өлеш	10	10	24	Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр
4 нче өлеш	6	20	49	Киңәйтелгән җавапны таләп иткән биремнәр
Барлыгы	27	41	100	

4. Имтихан эше биремнәрен эчтәлекләре һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү

Имтихан эшендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендәге рус телле укучыларның татар телендә коммуникатив компетенциягә ия булулары тикшерелә. Ягъни:

- тыңланган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белү: 1 нче бүлек биремнәре;

- укылган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белү: 2 нче бүлек биремнәре;

- тел берәмлекләрен коммуникатив яктан мөһим булган контекстта куллану күнекмәләренә ия булу: 3 нче бүлек биремнәре;
- тәкъдим ителгән сөйләм ситуацияләре буенча репликалар яза белү: 4 нче бүлек биремнәре;
- стимул-хатка җавап итеп шәхси хат яза белү: 4 нче бүлек биремнәре тәкъдим ителә.

Әлеге бүленеш 2 нче таблицада күрсәтелә.

Сөйләм осталыгы һәм тел берәмлекләрен куллану күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр бүленеше

2 нче таблица

Сөйләм осталыгы һәм тел күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр	Биремнәрнең саны	Иң югары башлангыч балл
Тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау	5	5
Тыңланган тексттагы кирәкле мәгълүматны аңлау	1	1
Укылган текстның төп эчтәлеген аңлау	2	2
Укылган тексттагы кирәкле мәгълүматны аңлау	3	3
Грамматик күнекмәләр	5	5
Лексик-грамматик күнекмәләр	5	5
Сөйләм бурычын аңлау күнекмәләре Сөйләм ситуациясенә караган репликаларны язу	5	10
Шәхси хат язу	1	10
Барлыгы	27	41

5. Имтихан эше биремнәрен катлаулылыгы дәрәҗәсеннән чыгып бүлү

Имтихан эше биремнәрен катлаулылыгы дәрәҗәсеннән чыгып бүлү 3 нче таблицада күрсәтелә.

Имтихан эшенең катлаулылык дәрәҗәсе тел материалының һәм тикшерелә торган күнекмәләрнең катлаулылыгы дәрәҗәсеннән, шулай ук биремнең төреннән чыгып билгеләнә.

Имтихан эшендә 2 төрле катлаулылыктагы биремнәр тәкъдим ителә.

Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше

3 *нче таблица*

Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе	**Биремнәрнең саны**	**Иң югары башлангыч балл**	**Иң югары башлангыч баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге өлеше өчен куелган иң югары башлангыч баллның проценты**
Беренче дәрәҗә	15	15	37
Икенче дәрәҗә	12	26	63
Барлыгы	27	41	100

6. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы

Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган һәм кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәргә дөрес җавап биргән өчен, укучы 1 балл ала. Җавап дөрес булмаса яки бөтенләй бирелмәсә, 0 балл куела.

6 нчы биремдә дөрес тәңгәлләкләр өчен укучы шулай ук 1 балл ала. Балл барлык тәңгәллекләр дөрес тәртиптә бирелгән очракта гына куела. Бер яки берничә тәңгәллек дөрес күрсәтелмәсә, укучы 0 балл ала. .

4 нче бүлек биремнәрен тикшерү махсус әзерләнгән критерийлар нигезендә башкарыла һәм укучыга имтиханның бу өлешендә барлыгы 20 балл куела. 11-16нчы биремнәрдә, сөйләм бурычын аңлап, аңа туры килгән 5 реплика язарга кирәк. Һәр реплика максималь 2 балл белән бәяләнә. Сөйләм репликалары барысы да дөрес язылса, укучы 10 балл ала.

27 нче биремне тикшергәндә, язма эшнең күләме, андагы сүзләрнең саны да исәпкә алына. Укучыдан 70-80 (җиңеләйтелгән биремнәрне башкаручылар 30-40) сүздән торган ижади эш язу сорала. Язма эшнең эчтәлеге һәм грамоталылыгы өчен укучы 10 балл ала. Эшнең күләме 40 (20) сүздән артмаса, текстның лексик-грамматик төзелеше (К3), орфография һәм пунктуация (К4) критерийлары өчен эшкә максималь балл куелмый.

Укучыга, гомумән, имтихан эше өчен максималь 41 балл куела.

Имтихан үтү алдыннан укучыларның әлеге эше өчен куела торган минималь баллның күләме билгеләнә. Ул тулы (урта) мәктәпнең 11 сыйныфында укучы рус телле укучыларның татар теленнән белем һәм күнекмәләренең минималь күләмен ачыклый.

Минималь баллдан югарырак баллар җыйган укучы түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау;
- тыңланган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау;
- укылган текстның төп эчтәлеген аңлау;
- укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау;

- лексик-грамматик һәм орфографик күнекмәләргә ия булу;
- билгеле бер тема, проблема буенча язма сөйләм һәм сөйләм ситуацияләренә караган репликаларны язу күнекмәләре.

Эшнең барлык үтәлгән биремнәре нигезендә 100 баллы шкала буенча тест баллары билгеләнә. Алар югары уку йортларына керү өчен файдаланыла.

7. Эшне башкару вакыты

Имтихан эшен үтәү өчен, 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

1 нче өлештә 6 бирем тәкъдим ителә (1-6 нчы биремнәр). Алар укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Башкару вакыты – 30 минут.

2 нче өлештә 5 бирем бирелә (7-11 нче биремнәр). Алар укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. Башкару вакыты – 20 минут.

3 нче өлеш 10 биремнән тора (12 –21 нче биремнәр). Алар укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. Башкару вакыты – 30 минут.

4 нче өлеш 6 биремнән тора (22-26 нчы һәм 27 нче биремнәр). Ачык типтагы 22-26 нчы биремнәр сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тота. Башкару вакыты - 30 минут. 27 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүдән гыйбарәт. Башкару вакыты - 40 минут.

8. 2026 нчы елгы контроль бәяләү материалларындагы үзгәрешләр

Бердәм республика имтиханы биремнәре сөйләм компетенцияләрен булдыруны тикшерү максатыннан үзгәртелделәр. Алар 9 нчы сыйныф укучылары тарафыннан тапшырыла торган төп дәүләт имтиханы критерийлары белән тәңгәл киләләр.

9. Бердәм республика имтиханын үткәрү һәм эшләрне тикшерүгә куелган таләпләр

Бердәм республика имтиханы махсус пунктларда уздырыла. Әлеге пунктлар гомуми белем бирү оешмалары базасында оештырыла.

Татар теленнән имтихан үткәрелә торган бүлмәләргә татар теле һәм әдәбияты белгечләре кертелми.

Имтиханны үткәрүдә андагы укучылар белән эшләмәгән педагог кына катнаша ала.

Имтиханның барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, укучыларга орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

1 нче номерлы җаваплар бланкы (1 – 21 нче биремнәрнең җаваплары язылган бланк) сканерланганнан соң, автоматик эшкәртүгә тапшырыла.

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнең дөреслеген махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

Киңәйтелгән җавап биремнәре ике эксперт-укытучы тарафыннан тикшерелә. Куелган баллар арасында 6 балл аерма булса, эш өченче тикшерүгә чыга һәм өченче эксперт бәясе дөрес дип санала.

Кушымта

2026 нчы елгы бердәм республика имтиханының туган (татар) теле буенча контроль бәяләү материаллары вариантының гомумиләштерелгән планы

Эштә һәм җавап бланкларында биремнәрне билгеләү: А - җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, В - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр, С – укучының укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнәр.

Шартлы кыскартулар: ВО - *җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр; КО - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр; РО - киңәйтелгән җавап (язма текст) бирүне таләп иткән биремнәр.*

Биремнәр-нең номеры	Тикшерелә торган эшчәнлек төре	Тикшере-лә торган элементның коды	Катлаулык дәрәҗәсе	Биремнең тибы	Тәкъдим ителә торган вакыт
1.	Тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау	1.1	1	ВО	30
2.			1	ВО	
3.			1	ВО	
4.			1	ВО	
5.			1	ВО	
6.	Тыңланган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау	1.2	2	ВО	30
7.	Укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау	2.1, 2.3	1	ВО	20
8.			1	ВО	
9.			1	ВО	
10.	Укылган текстның төп эчтәлеген аңлау	2.1, 2.2, 2.3,	2	ВО	
11.				ВО	
12.	Бирелгән сүзне кирәкле грамматик формада куллану күнекмәләре	4.1	1	КО	30 мин
13.			1	КО	
14.			1	КО	
15.			1	КО	
16.			1	КО	
17.		4.2	2	КО	

Биремнәр-нең номеры	**Тикшерелә торган эшчәнлек төре**	**Тикшере-лә торган элементның коды**	**Катлаулык дәрәҗәсе**	**Биремнең тибы**	**Тәкъдим ителә торган вакыт**
18.	Тамырдаш сүзләр ясау һәм аларны кирәкле грамматик формада куллануны таләп иткән лексик-грамматик күнекмәләр		2	КО	
19.			2	КО	
20.			2	КО	
21.			2	КО	
22.	Төрле сөйләм ситуацияләренә караган репликаларны язу	3.4, 3.5	2	РО	30 мин
23.			2	РО	
24.			2	РО	
25.			2	РО	
26.			2	РО	
27.	Сорауларга җавап биреп, шәхси хат язу	3.1, 3.2, 3.3, 3.5	2	РО	40 мин
Барлыгы 27 бирем. Шуларның: биремнәрнең төре буенча: ВО – 11, КО – 10, РО – 6. катлаулылык дәрәҗәсе буенча: 1 дәрәҗә – 15 бирем; 2 дәрәҗә – 12 бирем. Эшне башкару вакыты – 180 мин.					